**Карар № 61**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Советы**

Түбән Көек авылы 13 апрель 2023 ел

**Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Түбән Көек авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 20 февралендәге №09/13-09/779 номерлы хокукый экспертизасына һәм Әтнә районы прокуратурасының 2023 елның 2 мартындагы №02-08-02-2023/Прдп71-23 номерлы протестына таянып, Түбән Көек авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан баш тартса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең – физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым түләүче – физик затның суд карары нигезендә ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булуы бурычлы кешенең ирегеннән мәхрүм итү урыннарында булу чорына;

4) бурычлы кешенең мөлкәте булмаганда, Россия Федерациясеннән читтә калган физик затның җирле салымнарны түләү буенча бурычы барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану;

5) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы.

2. Үз көчен югалткан дип таныврга:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 25.10.2019 елның 103 номерлы карары «Җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм бу салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»;

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 22.12.2022 №55 номерлы карары “Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №103 номерлы “Җирле салымнар буенча бурычларны, бу салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында” гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”.

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча хэм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Д.М. Галиәхмәтов